| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. №423-12/тко2022

«Чиста шәһәр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2021 №372-34/тко-2021 карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022-2024 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022-2024 елларга «Чиста шәһәре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 24.11.2021 №372-34/тко-2021 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

түбәндәге таблица графаларын

| « 2022 ел | |
|---|---|
| 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 173,73 | 173,73 » |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге таблица графаларын

| « 2023 | | 2024 | |
|---|---|---|---|
| 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 173,73 | 182,17 | 182,17 | 182,42» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «2023 ел | 2024 ел | |
|---|---|---|
| 174,27 | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | 174,27 | 189,11»; |

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга чик тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2021 №372-34/тко-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 №423-12/тко2022 карары редакциясендә) 2 нче кушымта

## «Чиста шәһәр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2022 – 2024 елларга чик тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2022 | 15 326,48 | 1 | 0 | 0,38 |
| | | 2023 | х | 1 | 0 | 0,38 |
| | | 2024 | х | 1 | 0 | 0,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге